**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об инновационной деятельности в Республике Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
22 апреля 2019 года

## Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 2 августа 2010 года № 63-ЗРТ «Об инновационной деятельности в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2010, № 8 – 9; 2012, № 1; 2014, № 5, № 6 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 22 (часть I) следующие изменения:

1) в части 1 статьи 2:

а) пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1) инновационная политика Республики Татарстан – составная часть социально-экономической политики, которая выражает отношение республики к инновационной деятельности, определяет цели, направления, формы деятельности органов государственной власти Республики Татарстан в области науки, техники, технологий и реализации достижений науки, техники и технологий;»;

б) пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2) инновационный продукт:

первого уровня – не имеющий мировых аналогов конечный результат инновационной деятельности, получивший воплощение в виде нового или усовершенствованного серийно выпускаемого продукта (товара, работы, услуги), используемого в серийном производстве производственного процесса, нового маркетингового или организационного метода – в ведении бизнеса, организации рабочего места, внешних связях;

второго уровня – конечный результат инновационной деятельности, получивший воплощение в виде нового или усовершенствованного серийно выпускаемого продукта (товара, работы, услуги), используемого в серийном

производстве производственного процесса, нового маркетингового или организационного метода – в ведении бизнеса, организации рабочего места, внешних связях, новых для практики предприятия или для рынка страны;»;

в) пункт 7 признать утратившим силу;

г) пункт 8 изложить в следующей редакции:

«8) бизнес-инкубатор – юридическое лицо, относящееся к инфраструктуре поддержки субъектов малого и среднего предпринимательства, созданное в целях поддержки предпринимателей на ранней стадии их деятельности – стадии, при которой срок деятельности субъекта малого и среднего предпринимательства с момента государственной регистрации до момента подачи заявки на участие в конкурсе на предоставление в аренду помещений и оказание услуг бизнес-инкубатором не превышает трех лет, осуществляющее такую поддержку путем предоставления в аренду помещений и оказания услуг, необходимых для ведения предпринимательской деятельности, в том числе консультационных, бухгалтерских и юридических услуг, а также проведения образовательных тренингов и семинаров;»;

д) дополнить пунктами 9 – 11 следующего содержания:

«9) технопарк в сфере высоких технологий – управляемый управляющей компанией комплекс объектов коммунальной, транспортной и технологической инфраструктуры, зданий, строений, сооружений и оборудования, предназначенный для обеспечения полного цикла услуг по размещению и развитию инновационных компаний, являющихся резидентами технопарка, а также запуска и выведения на рынок высокотехнологичной продукции, услуг и технологий, в том числе за счет территориальной интеграции с научными и (или) образовательными организациями;

10) центр инжиниринга – юридическое лицо, основным видом деятельности которого является повышение технологической готовности промышленных предприятий к освоению новых видов продукции и внедрению инноваций за счет поддержки разработки конструкторской и технологической документации, технологических процессов и обеспечения решения проектных, инженерных, технологических и организационно-внедренческих задач, возникающих при организации серийного производства;

11) центр прототипирования – юридическое лицо или структурное подразделение юридического лица, относящееся к инфраструктуре поддержки субъектов малого и среднего предпринимательства, основным видом деятельности которого является оказание услуг по созданию макетов, прототипов, опытных образцов и иной мелкосерийной продукции на этапах от компьютерного проектирования до изготовления продукции.»;

2) статью 3 после слова «иных» дополнить словом «нормативных»;

3) пункт 5 части 1 статьи 4 изложить в следующей редакции:

«5) организации (субъекты) инновационной инфраструктуры (технополисы, инновационные фонды, венчурные фонды, технопарки, бизнес-инкубаторы,

управляющие компании технопарков в сфере высоких технологий, центры инжиниринга, центры прототипирования, иные субъекты инновационной инфраструктуры);»;

4) в части 2 статьи 7:

а) в пункте 3 слова «финансового капитала» заменить словом «средств»;

б) дополнить пунктом 6 следующего содержания:

«6) обеспечение роста объема выпуска инновационной продукции (товаров, работ, услуг).»;

5) в статье 9:

а) в части 1:

пункт 1 после слова «инновационной» дополнить словами «и научно-технической»;

в пункте 3 слова «стратегии инновационного развития Республики Татарстан и разработанных на ее основе республиканских целевых инновационных программ» заменить словами «государственных программ Республики Татарстан, содержащих мероприятия в сфере поддержки инновационной и научно-технической деятельности»;

в пункте 4 слова «стратегии инновационного развития Республики Татарстан и разработанных на ее основе республиканских целевых инновационных программ» заменить словами «государственных программ Республики Татарстан, содержащих мероприятия в сфере поддержки инновационной и научно-технической деятельности»;

б) в части 2:

пункт 1 признать утратившим силу;

пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2) систему ориентиров инновационного развития Республики Татарстан, закрепленных в стратегии социально-экономического развития Республики Татарстан;»;

пункт 3 изложить в следующей редакции:

«3) государственные программы Республики Татарстан, содержащие мероприятия в сфере поддержки инновационной и научно-технической деятельности;»;

в пункте 5 слова «в целом и по каждой программе (каждому мероприятию) в отдельности» исключить;

6) статью 10 признать утратившей силу;

7) статью 11 признать утратившей силу;

8) часть 2 статьи 12 изложить в следующей редакции:

«2. Государственный доклад об итогах инновационной деятельности в Республике Татарстан утверждается Кабинетом Министров Республики Татарстан и подлежит размещению на официальном сайте уполномоченного органа исполнительной власти в области инновационной деятельности в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».»;

9) статью 13 изложить в следующей редакции:

«Статья 13. **Государственные программы Республики Татарстан, содержащие мероприятия в сфере поддержки инновационной и научно-технической деятельности**

1. Государственные программы Республики Татарстан могут содержать мероприятия, направленные на развитие инновационной и научно-технической деятельности.

2. Порядок организации проведения экспертизы научно-исследовательских, опытно-конструкторских и технологических работ и инновационных проектов, предлагаемых для дальнейшей реализации за счет средств бюджета Республики Татарстан в рамках мероприятий в сфере государственной поддержки инновационной и научно-технической деятельности, включаемых в государственные программы Республики Татарстан, определяется уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области инновационной деятельности.»;

10) в статье 14:

а) пункт 2 признать утратившим силу;

б) в пункте 3 слова «экономическое обоснование» заменить словами «технико-экономическое обоснование»;

в) в пункте 4 слова «правозащищенность инновационного проекта» заменить словами «сведения о состоянии правовой охраны результатов интеллектуальной деятельности, используемых при реализации инновационных проектов»;

г) в пункте 6 слова «, являющееся всесторонней оценкой материалов вносимого инновационного проекта» исключить;

11) в статье 16:

а) пункт 2 части 2 признать утратившим силу;

б) в пункте 2 части 3 слова «республиканскую целевую инновационную программу, инновационный меморандум Республики Татарстан» заменить словами «государственные программы Республики Татарстан, содержащие мероприятия в сфере поддержки инновационной и научно-технической деятельности»;

в) в части 4:

пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1) разрабатывает систему ориентиров инновационного развития Республики Татарстан;»;

пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2) обеспечивает организацию проведения экспертизы научно-исследовательских, опытно-конструкторских, технологических работ и инновационных проектов;»;

пункт 3 изложить в следующей редакции:

«3) разрабатывает государственные программы Республики Татарстан, содержащие мероприятия в сфере поддержки инновационной и научно-технической деятельности;»;

в пункте 5 слова «в соответствии с целевыми ориентирами их деятельности, утвержденными инновационным меморандумом Республики Татарстан» исключить;

12) в части 1 статьи 17:

а) пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1) разработка, реализация и финансирование государственных программ Республики Татарстан, содержащих мероприятия в сфере поддержки инновационной и научно-технической деятельности;»;

б) в пункте 4 слова «законодательствам Российской Федерации и Республики Татарстан» заменить словами «законодательству Российской Федерации и законодательству Республики Татарстан»;

в) пункт 7 изложить в следующей редакции:

«7) содействие общественным объединениям в инновационной и научно-технической сферах;»;

г) пункт 8 после слова «популяризации» дополнить словами «инновационной и»;

д) пункт 9 изложить в следующей редакции:

«9) учреждение республиканских ежегодных премий и грантов в области науки и техники.»;

13) статью 19 изложить в следующей редакции:

«Статья 19. **Финансирование государственной поддержки инновационной деятельности**

Финансирование государственной поддержки инновационной деятельности осуществляется Российской Федерацией и Республикой Татарстан с учетом основных направлений государственной поддержки.»;

14) статью 20 изложить в следующей редакции:

«Статья 20. **Ответственность субъектов инновационной деятельности**

1. Субъекты инновационной деятельности при несоблюдении законодательства, а также в случае нецелевого использования средств, предоставляемых на осуществление инновационной деятельности, несут имущественную и иную ответственность, предусмотренную законодательством.

2. Споры, возникающие при осуществлении инновационной деятельности, разрешаются в порядке, предусмотренном законодательством Российской Федерации.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан | Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
29 апреля 2019 года
№ 34-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 8 – 9; 2012, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Татарстан Республикасының инновация сәясәте – социаль-икътисадый сәясәтнең инновация эшчәнлегенә республиканың мөнәсәбәтен белдерә торган, фән, техника, технологияләр һәм фән, техника һәм технологияләр казанышларын гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары эшчәнлегенең максатларын, юнәлешләрен, рәвешләрен билгели торган состав өлеше;»;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) инновация продукты:

беренче дәрәҗәдәге – инновация эшчәнлегенең җитештерү процессында серияле эшләп чыгаруда кулланыла торган серияле чыгарылучы яңа яисә камилләштерелгән продукт (товар, эш, хезмәтләр күрсәтү), бизнес алып баруда, эш урыннарын оештыруда, тышкы элемтәләрдә яңа маркетинг яисә оештыру алымы рәвешендә чагылыш тапкан дөньяда аналогы булмаган соңгы нәтиҗәсе;

икенче дәрәҗәдәге – инновация эшчәнлегенең җитештерү процессында серияле эшләп чыгаруда кулланыла торган серияле чыгарылучы яңа яисә камилләштерелгән продукт (товар, эш, хезмәтләр күрсәтү), предприятие яки ил базары практикасы өчен яңа булган бизнес алып баруда, эш урыннарын оештыруда,

тышкы элемтәләрдә яңа маркетинг яисә оештыру алымы рәвешендә чагылыш тапкан соңгы нәтиҗәсе;»;

в) 7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

г) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) бизнес-инкубатор – кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасына керә торган, эшкуарларга эшчәнлекләренең башлангыч чорында – дәүләт теркәвенә алынган мизгелдән алып бизнес-инкубатор тарафыннан арендага биналар бирүгә һәм хезмәтләр күрсәтүгә конкурста катнашуга гариза бирү мизгеленә кадәр кече һәм урта эшкуарлык субъектының эшчәнлек срогы өч елдан артмаган чорда ярдәм күрсәтү максатыннан оештырылган, мондый ярдәмне арендага биналар бирү һәм эшкуарлык эшчәнлеген алып бару өчен кирәкле хезмәтләр күрсәтү, шул исәптән консультация бирү, бухгалтерлык һәм юридик хезмәтләр, шулай ук белем бирү тренинглары һәм семинарлары уздыру юлы белән гамәлгә ашыра торган юридик зат;»;

д) түбәндәге эчтәлекле 9 – 11 пунктлар өстәргә:

«9) югары технологияләр өлкәсендә технопарк – технопарк резидентлары булып торучы инновация компанияләрен урнаштыру һәм үстерү буенча хезмәтләр күрсәтүнең тулы циклын тәэмин итү өчен, шулай ук югары технологияле продукцияне, хезмәтләр күрсәтүне һәм технологияләрне, шул исәптән фәнни оешмалар һәм (яисә) мәгариф оешмалары белән территориаль интеграция исәбенә, эшләтеп җибәрү һәм базарга чыгару өчен каралган коммуналь, транспорт һәм технология инфраструктурасы объектларының, биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм җиһазларның идарәче компания тарафыннан идарә ителә торган комплексы;

10) инжиниринг үзәге – төп эшчәнлек төре сәнәгать предприятиеләренең яңа төр продукцияне үзләштерүгә һәм конструкторлык, технологик документлар, технологик процесслар эшләүгә ярдәм итү һәм серияле җитештерүне оештырганда килеп чыга торган проектлау, инженерлык, технологик һәм оештыру-гамәлгә ашыру мәсьәләләрен чишүне тәэмин итү исәбенә инновацияләр кертүгә технологик әзерлеген арттырудан гыйбарәт булган юридик зат;

11) прототиплаштыру үзәге – кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасына керә торган, төп эшчәнлек төре компьютерда проектлаудан алып продукцияне эшләп чыгару этапларына кадәр макетлар, прототиплар, тәҗрибә уздыру үрнәкләре һәм башка аз серияле продукция ясау буенча хезмәтләр күрсәтүдән гыйбарәт булган юридик зат яки юридик затның структур бүлекчәсе.»;

2) 3 статьяга «башка» сүзеннән соң «норматив» сүзен өстәргә;

3) 4 статьяның 1 өлешенең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) инновация инфраструктурасы оешмалары (субъектлары) (технополислар, инновация фондлары, венчур фондлары, технопарклар, бизнес-инкубаторлар, югары технологияләр өлкәсендә технопаркларга идарәче компанияләр, инжиниринг

үзәкләре, прототиплаштыру үзәкләре, инновация инфраструктурасының башка субъектлары);»;

4) 7 статьяның 2 өлешендә:

а) 3 пунктта «финанс капиталын» сүзләрен «акчаларын» сүзенә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) инновация продукциясен (товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү) чыгару күләме үсешен тәэмин итү.»;

5) 9 статьяда:

а) 1 өлештә:

1 пунктта «эшчәнлегенең» сүзеннән соң «һәм фәнни-техник эшчәнлекнең» сүзләрен өстәргә;

3 пунктта «Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясен һәм аның нигезендә эшләнгән республика максатчан инновация программаларын» сүзләрен «инновация эшчәнлегенә һәм фәнни-техник эшчәнлеккә ярдәм итү өлкәсендәге чаралар кергән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасын инновацион үстерү стратегиясен һәм аның нигезендә эшләнгән республика максатчан инновация программаларын» сүзләрен «инновация эшчәнлегенә һәм фәнни-техник эшчәнлеккә ярдәм итү өлкәсендәге чаралар кергән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә:

1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясендә билгеләнгән Татарстан Республикасын инновацион үстерү ориентирлары системасын;»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) инновация эшчәнлегенә һәм фәнни-техник эшчәнлеккә ярдәм итү өлкәсендәге чаралар кергән Татарстан Республикасы дәүләт программалары;»;

5 пунктта «тулаем һәм аның һәр программасы (һәр чарасы) буенча аерым» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 10 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 11 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

8) 12 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында дәүләт докладлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана һәм

башкарма хакимиятнең инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.»;

9) 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 статья. **Инновация эшчәнлегенә һәм фәнни-техник эшчәнлеккә ярдәм итү өлкәсендәге чаралар кергән Татарстан Республикасы дәүләт программалары**

1. Татарстан Республикасының дәүләт программаларында инновация эшчәнлеген һәм фәнни-техник эшчәнлекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар булырга мөмкин.

2. Инновация эшчәнлегенә һәм фәнни-техник эшчәнлеккә дәүләт ярдәме өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертелә торган чаралар кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән алга таба гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләргә һәм инновация проектларына экспертиза уздыруны оештыру тәртибе Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.»;

10) 14 статьяда:

а) 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 3 пунктта «икътисадый нигезләү» сүзләрен «техник-икътисадый нигезләү» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктта «инновация проектының хокукый якланышын» сүзләрен «инновация проектларын гамәлгә ашырганда файдаланыла торган интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренең хокукый якланышы торышы турындагы белешмәләрне» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктта «кертелүче инновация проекты материалларын һәрьяклап бәяли торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

11) 16 статьяда:

а) 2 өлешнең 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 3 өлешнең 2 пунктында «республика максатчан инновация программасын, Татарстан Республикасы инновация меморандумын» сүзләрен «инновация эшчәнлегенә һәм фәнни-техник эшчәнлеккә ярдәм итү өлкәсендәге чаралар кергән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Татарстан Республикасын инновацион үстерү ориентирлары системасын эшли;»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык, технологик эшләр һәм инновация проектларына экспертиза уздыруны оештыруны тәэмин итә;»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) инновация эшчәнлегенә һәм фәнни-техник эшчәнлеккә ярдәм итү өлкәсендәге чаралар кергән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшли;»;

5 пунктта «эшчәнлекләренең Татарстан Республикасы инновация меморандумында расланган максатчан ориентирлары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

12) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) инновация эшчәнлегенә һәм фәнни-техник эшчәнлеккә ярдәм итү өлкәсендәге чаралар кергән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм финанслау;»;

б) 4 пунктта «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) иҗтимагый берләшмәләргә инновация өлкәсендә һәм фәнни-техник өлкәдә ярдәм күрсәтү;»;

г) 8 пунктта «Татарстан Республикасында» сүзләреннән соң «инновация эшчәнлеген һәм» сүзләрен өстәргә;

д) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) фән һәм техника өлкәсендә еллык республика премияләрен һәм грантларын гамәлгә кую.»;

13) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19 статья. **Инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен финанслау**

Инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен финанслау, дәүләт ярдәменең төп юнәлешләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

14) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20 статья. **Инновация эшчәнлеге субъектларының җаваплылыгы**

1. Инновация эшчәнлеге субъектлары законнарны үтәмәгәндә, шулай ук инновация эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бирелә торган акчалардан максатчан файдаланмаган очракта мөлкәти һәм законнарда каралган башка төрле җаваплылыкка ия булалар.

2. Инновация эшчәнлеген гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган бәхәсләр Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә хәл ителә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 29 апрель
№ 34-ТРЗ